**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXIV УТЫРЫШЫ

**Карар № 36**

Октябрь ав. 26.07 2022 ел.

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләргә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» Октябрь авыл җирлеге Советы 2014 елның 18 нче декабрендәге 61 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы **Октябрь** авыл җирлегенең муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук муниципаль хезмәткәрләргә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 18 нче декабрендәге 61 нче номерлы Октябрь авыл җирлеге Советы карары, 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында

буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2016 елның 23 нче мартындагы 14 нче номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан сон үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М.Ханнанов